1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнар, әлеге Закон белән билгеләнә, һәм аларга үз вәкаләтләре һәм Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган вәкаләтләр керә.
2. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган ике һәм аннан артыграк субъектының территориаль планлаштыру схемасы проектын, Россия

Федерациясенең Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган субъектының территориаль планлаштыру схемасы проектын килештерү;

2) Россия Федерациясенең ике һәм аннан артыграк субъектының территориаль планлаштыру схемасы проекты Татарстан Республикасы территориясенә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешләренә карата әзерләнгән очракта, әлеге схеманы, Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау;

3) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда территорияне планлаштыру документларын раслау;

4) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда муниципаль районнарның территориаль планлаштыру схемалары проектларын, җирлекләрнең генераль планнары проектларын, шәһәр округларының генераль планнары проектларын, җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын килештерү;

5) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясындагы 20 өлеше нигезендә төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге тәртибен билгеләү;

6) региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау тәртибен билгеләү;

7) җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләү һәм раслау мониторингын гамәлгә ашыру;

8) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларын булдыру һәм алардан файдалану, шул исәптән мондый мәгълүмат системаларын шәһәр төзелеше эшчәнлеген ике һәм аннан артыграк муниципаль район, шәһәр округы территорияләрендә гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештә алып бару;

9) шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын раслау;

10) Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын алып бару тәртибен билгеләү;

11) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы органнарын билгеләү;

12) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектына җыелма бәяләмә, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган ике һәм аннан артыграк субъектының территориаль планлаштыру схемасы проектын, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган субъектының территориаль планлаштыру схемасы проектын килештерү (килештерүдән баш тарту) турында бәяләмәләр әзерләүне тәэмин итү;

2) Россия Федерациясенең ике һәм аннан артыграк субъектының территориаль планлаштыру схемасы проекты Татарстан Республикасы территориясенә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешләренә карата әзерләнгән очракта, әлеге схеманы, Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү;

4) шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын әзерләү;

5) әлеге Законның $14^1$ статьясы нигезендә шәһәр төзелешен проектлауның республика һәм җирле нормативларын системага салу;

6) әгәр «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын гамәлгә кертү турында» 2004 елның 29 декабрендәге 191-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6 статьясындагы 1 өлешенең $5^1$ пунктында күрсәтелгән проектлау документларына дәүләт экспертизасыннан, инженер эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасыннан тыш, проектлау документларына дәүләт экспертизасы, инженер эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы оештыру һәм уздыру;

7) җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору;

8) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру;

9) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $51^1$ статьясындагы 7 өлешендәге 2 пунктында, 8 өлешендәге 3 пунктында һәм 55 статьясындагы 19 өлешенең 5 пунктында каралган хәбәрнамәләрне җибәрү;

10) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $2^2$ статья өстәргә:

«$2^2$ статья. **Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.»;

4) 4 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасын» сүзләре алдыннан «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 14 статьясындагы 8 һәм 9 өлешләренең нигезләмәләренә таянып,» сүзләрен өстәргә;

5) 6 статьяның 4 өлешендә «Муниципаль» сүзе алдыннан «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 19 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләренең нигезләмәләренә таянып,» сүзләрен өстәргә;

6) 9 статьяның 5 өлешендә «Генераль» сүзе алдыннан «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләренең нигезләмәләренә таянып,» сүзләрен өстәргә;

7) 18 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктта татарча текст үзгәрешсез кала;

3 пунктта «пункты» сүзен «өлеше» сүзенә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «йә күрсәтелгән органның ведомство буйсынуындагы дәүләт (бюджет яисә автоном) учреждениеләре» сүзләрен «, күрсәтелгән органның ведомство буйсынуындагы дәүләт (бюджет яисә автоном) учреждениеләре» сүзләренә алмаштырырга;

8) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Региональ әһәмияттәге объектлар**

1. Региональ әһәмияттәге объектлар Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карамагына кертелгән мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясый торган капиталь төзелеш объектларыннан, башка объектлардан, территорияләрдән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасында чагылдырылырга тиешле региональ әһәмияттәге объектлар төрләренә түбәндәгеләр керә:

1) транспорт (тимер юл, су, һава, автомобиль), региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә:

а) региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары, ясалма юл корылмалары (күперләр, юлүткәргечләр, торба үткәргечләр, тоннельләр, эстакадалар, шундый төрдәге корылмалар), мондый автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары чикләрендә яисә юл буе полосалары чикләрендә урнаштырыла торган юл сервисы объектлары, автомобиль транспортын куеп тору урыннары (парковкалар);

б) региональ әһәмияттәге муниципальара юлларда халыкка автомобиль һәм тимер юл транспорты хезмәт күрсәтүләрен оештыру өчен кирәкле объектлар, транспорт-күчеп утыру узеллары, тимер юл транспорты объектлары;

в) Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге, аэропортларны һәм (яисә) аэродромнарны, вертодромнарны, граждан авиациясе төшү мәйданчыкларын карап тоту, үстерү һәм алардан файдалануны оештыру өчен кирәкле объектлар;

г) Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге, елга портларын карап тоту, үстерү һәм алардан файдалануны оештыру өчен кирәкле объектлар;

2) региональ һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны, эпидемияләрне кисәтү һәм аларның зыяннарын бетерү өлкәсендә:

а) региональ әһәмияттәге объектларны саклауны тәэмин итә торган яисә ике һәм аннан артыграк муниципаль район территорияләрендә урнашкан, гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны, эпидемияләрне кисәтү һәм аларның зыяннарын бетерү өчен кирәкле инженерлык саклавы объектлары һәм гидротехник корылмалар;

б) Татарстан Республикасының һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм Татарстан Республикасының һәлакәттән коткару формированиеләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле объектлар;

в) гражданнар оборонасы чараларын региональ һәм муниципальара дәрәҗәдә оештыру өчен кирәкле объектлар;

г) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге вәкаләтләре нигезендә Дәүләт янгынга каршы хезмәте көчләре белән янгыннарны сүндерүне оештыру өчен билгеләнгән объектлар;

3) мәгариф өлкәсендә:

а) үзләрендә (үз территорияләрендә) гомуми белем бирү оешмалары, шул исәптән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары, озакка сузылган дәвалауга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмалары, ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләре урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы объектлар;

б) үзләрендә (үз территорияләрендә) һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы объектлар, мондый белем бирү оешмаларының тулай тораклары;

в) үзләрендә (үз территорияләрендә) өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы объектлар;

г) үзләрендә (үз территорияләрендә) ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы объектлар;

д) үзләрендә (үз территорияләрендә) мәгариф оешмалары урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы башка объектлар;

е) үзләрендә (үз территорияләрендә) фәнни оешмалар урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы объектлар;

4) сәламәтлек саклау өлкәсендә: үзләрендә (үз территорияләрендә) медицина оешмалары урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы объектлар;

5) физик культура һәм спорт өлкәсендә:

а) региональ әһәмияттәге спорт объектлары;

б) үзләрендә (үз территорияләрендә) физкультура-спорт оешмалары урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы объектлар;

6) энергетика өлкәсендә:

а) көчәнешләренең проектлы номиналь классы 110 (150) кВ тәшкил итә торган электр тапшыру линияләре (һава һәм кабельле);

б) көчәнешләренең проектлы номиналь классы 110 (150) кВ тәшкил итә торган подстанцияләр;

в) көчәнешләренең проектлы номиналь классы 35 кВ тәшкил итә торган электр тапшыру линияләре (һава һәм кабельле);

г) көчәнешләренең проектлы номиналь классы 35 кВ тәшкил итә торган подстанцияләр;

7) мәдәният өлкәсендә:

а) тарихи-архитектура, сәнгати, фәнни һәм мемориаль кыйммәткә, Татарстан Республикасы тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән Татарстан Республикасы территориясендәге объектлар, аларның территорияләре һәм аларны саклау зоналары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары һәм аларның территорияләре;

б) Татарстан Республикасы карамагында булган мәдәни-ял итү билгеләнешендәге объектлар, шул исәптән үзләрендә (үз территорияләрендә) музейлар, театрлар, күргәзмә заллары, китапханәләр, концерт заллары, филармонияләр урнашкан объектлар;

8) инженерлык инфраструктурасы өлкәсендә:

а) ике һәм аннан артыграк муниципаль район, шәһәр округы территорияләрендә урнашкан яисә урнаштыруы планлаштырыла торган, җирле үзидарә органнарының ике һәм аннан артыграк муниципаль районның, шәһәр округының инженерлык инфраструктурасын үстерү өлешендәге вәкаләтләрен тәэмин итү өчен кирәкле җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су җибәрү, элемтә объектлары һәм инженерлык инфраструктурасының башка объектлары;

б) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру өчен билгеләнгән, калдыклар, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән дә эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасының территориаль схемасына кертелгән объектлар;

9) Татарстан Республикасы вәкаләтләре нигезендә башка өлкәләрдә:

а) региональ әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләре;

б) региональ әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар;

в) табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген тәэмин итә торган региональ әһәмияттәге линия объектлары;

г) үзләрендә (үз территорияләрендә) социаль хезмәт күрсәтү, социаль яклау оешмалары һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре урнашкан Татарстан Республикасы карамагындагы объектлар;

д) Татарстан Республикасы карамагындагы күмү урыннары территорияләре;

е) Татарстан Республикасы карамагындагы сәнәгать-җитештерү, индустриаль-логистик, агросәнәгать комплекслары объектлары, файдалы казылмалар чыгару һәм эшкәртү сәнәгате объектлары;

ж) әлеге өлешнең 1 – 8 пунктларында, шулай ук әлеге пунктның «а» – «е» пунктчаларында күрсәтелмәгән, Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектлары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге җир кишәрлекләрендә яисә Татарстан Республикасы дәүләт

ихтыяҗлары өчен резервланган җир кишәрлекләрендә урнаштыру планлаштырыла торган объектлар;

з) әлеге өлешнең 1 – 8 пунктларында, шулай ук әлеге пунктның «а» – «е» пунктчаларында күрсәтелмәгән, гамәлдәге яисә төзелеше Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары белән билгеләнгән Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле юнәлешләре нигезендә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары;

и) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле объектлар.»;

9) 19[1] статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19[1] статья. **Муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектлары**

1. Муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектлары муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль районнар уставлары нигезендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм муниципаль районнарның социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясый торган капиталь төзелеш объектларыннан, башка объектлардан, территорияләрдән гыйбарәт.

2. Муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасында чагылдырылырга тиешле җирле әһәмияттәге объектлар төрләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итү өлкәсендә: муниципаль район составына керүче ике һәм аннан артыграк җирлек территорияләрендә урнашкан яисә урнаштыруы планлаштырыла торган электр һәм газ белән тәэмин итү объектлары;

2) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә:

а) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, ясалма юл корылмалары (күперләр, юлүткәргечләр, торба үткәргечләр, тоннельләр, эстакадалар, шундый төрдәге корылмалар), мондый автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары чикләрендә яисә юл буе полосалары чикләрендә урнаштырыла торган юл сервисы объектлары;

б) муниципаль район чикләрендә торак пунктлар арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен кирәкле транспорт объектлары;

3) мәгариф өлкәсендә:

а) үзләрендә (үз территорияләрендә) гомуми белем бирү оешмалары урнашкан муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

б) каникул вакытында балаларның ялын оештыру өчен кирәкле булган муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

в) үзләрендә (үз территорияләрендә) мәктәпкәчә белем бирү оешмалары урнашкан муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

4) сәламәтлек саклау өлкәсендә: үзләрендә (үз территорияләрендә) медицина оешмалары урнашкан муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

5) физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә:

а) муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы спорт объектлары;

б) үзләрендә (үз территорияләрендә) физкультура-спорт оешмалары урнашкан муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

6) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру өлкәсендә: каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру өчен билгеләнгән муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

7) мәдәният өлкәсендә:

а) тарихи-архитектура, сәнгати, фәнни һәм мемориаль кыйммәткә, муниципаль район тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия булган, муниципаль район территориясендә урнашкан, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар, аларның территорияләре һәм аларны саклау зоналары;

б) муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагында булган мәдәни-ял итү билгеләнешендәге объектлар, шул исәптән үзләрендә (үз территорияләрендә) район мәдәният йортлары, җирлекара китапханәләр, кинотеатрлар, музейлар, җирле традицияле халык сәнгать иҗатын һәм һөнәрләрне үстерү объектлары урнашкан объектлар;

8) муниципаль районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләре нигезендә башка өлкәләрдә:

а) муниципаль район составына керүче ике һәм аннан артыграк җирлек территорияләрендә урнашкан яисә урнаштыруы планлаштырыла торган су белән тәэмин итү, элемтә объектлары һәм инженерлык инфраструктурасының башка объектлары;

б) үзләрендә (үз территорияләрендә) эшчәнлекләре бердәм житештерү-технология процессы кысаларында гамәлгә ашырыла торган сәнәгать, агросәнәгать предприятиеләре яисә берничә предприятие урнашкан муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

в) муниципаль район чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның зыяннарын бетерү өчен, шулай ук гражданнар оборонасы, халыкны һәм муниципаль район территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

г) су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

д) муниципаль район территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү өчен билгеләнгән объектлар;

е) җирлекара күмү урыннары;

ж) муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагында булган җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар;

з) муниципаль районның җирле үзидарә органнары карамагында булган җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләре;

и) әлеге өлешнең 1 – 7 пунктларында, шулай ук әлеге пунктның «а» – «з» пунктчаларында күрсәтелмәгән, муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм муниципаль районның социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясый торган гамәлдәге яисә төзелеше муниципаль районның стратегик планлаштыру документлары белән билгеләнгән муниципаль районны социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле юнәлешләре нигезендә планлаштырыла торган объектлар.»;

10) $19^2$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$19^2$ статья. **Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектлары**

1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектлары җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, җирлек уставлары нигезендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм җирлекнең социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясый торган капиталь төзелеш объектларыннан, башка объектлардан, территорияләрдән гыйбарәт.

2. Җирлекнең генераль планында чагылдырылырга тиешле җирле әһәмияттәге объектлар төрләренә түбәндәгеләр керә:

1) халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су җибәрү өлкәсендә: законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су җибәрүне, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру өчен кирәкле объектлар;

2) җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә:

а) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, ясалма юл корылмалары (күперләр, юлүткәргечләр, торба үткәргечләр, тоннельләр, эстакадалар, шундый төрдәге корылмалар), мондый автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары чикләрендә яисә юл буе полосалары чикләрендә урнаштырыла торган юл сервисы объектлары;

б) җирлек чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен кирәкле транспорт объектлары;

3) мәдәният өлкәсендә:

а) тарихи-архитектура, сәнгати, фәнни һәм мемориаль кыйммәткә, җирлек тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия булган, җирлек территориясендә урнашкан, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән җирлекнең

җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар, аларның территорияләре һәм аларны саклау зоналары;

б) җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагында булган мәдәни-ял итү билгеләнешендәге объектлар, шул исәптән үзләрендә (үз территорияләрендә) мәдәният йортлары, китапханәләр, кинотеатрлар, халыкның ял итү үзәкләре, концерт заллары, күргәзмә заллары, музейлар урнашкан объектлар;

4) җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле рәвештә башка өлкәләрдә:

а) җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы спорт объектлары, үзләрендә (үз территорияләрендә) физкультура-спорт оешмалары урнашкан җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

б) җирлек чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның зыяннарын бетерү өчен, шулай ук гражданнар оборонасы, халыкны һәм җирлек территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

в) су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

г) җирлекнең җирле үзидарә органнарының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге вәкаләтләре нигезендә җирлек чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү гамәлләрен оештыру һәм тормышка ашыру өчен билгеләнгән объектлар;

д) үзләрендә (үз территорияләрендә) эшчәнлекләре бердәм җитештерү-технология процессы кысаларында гамәлгә ашырыла торган сәнәгать, агросәнәгать предприятиеләре яисә берничә предприятие урнашкан җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

е) җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы гаражлар, парковкалар, күпкатлы машина кую урыннары, логистика үзәкләре, склад территорияләре;

ж) элемтә объектлары, сәүдә объектлары, базар комплекслары, үзләрендә (үз территорияләрендә) җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте һәм коммуналь хезмәт күрсәтү предприятиеләре урнашкан җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

з) җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагында булган җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар;

и) җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагында булган җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләре;

к) җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы күмү урыннары, ритуаль хезмәт күрсәтү оешмаларының биналары һәм корылмалары;

л) әлеге өлешнең 1 – 3 пунктларында, шулай ук әлеге пунктның «а» – «к» пунктчаларында күрсәтелмәгән, җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм җирлекнең социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясый торган урнашкан яисә төзелеше җирлекнең стратегик планлаштыру документлары

белән билгеләнгән җирлекне социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле юнәлешләре нигезендә планлаштырыла торган объектлар.».

11) $19^3$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$19^3$ статья. **Шәһәр округының җирле әһәмияттәге объектлары**

1. Шәһәр округының җирле әһәмияттәге объектлары шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, шәһәр округлары уставлары нигезендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм шәһәр округларының социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясый торган капиталь төзелеш объектларыннан, башка объектлардан, территорияләрдән гыйбарәт.

2. Шәһәр округының генераль планында чагылдырылырга тиешле җирле әһәмияттәге объектлар төрләренә түбәндәгеләр керә:

1) халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су җибәрү өлкәсендә: законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә шәһәр округы чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су җибәрүне, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру өчен кирәкле объектлар;

2) җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә:

а) шәһәр округы чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, ясалма юл корылмалары (күперләр, юлүткәргечләр, торба үткәргечләр, тоннельләр, эстакадалар, шундый төрдәге корылмалар), мондый автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары чикләрендә яисә юл буе полосалары чикләрендә урнаштырыла торган юл сервисы объектлары;

б) шәһәр округы чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен кирәкле транспорт объектлары, шул исәптән шәһәр рельслы транспорт, гомуми юллардан тыш юлларда йөри торган транспорт линияләре;

3) физик культура һәм массакүләм спорт, мәгариф, сәламәтлек саклау, каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру өлкәсендә:

а) шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы спорт объектлары, үзләрендә (үз территорияләрендә) физкультура-спорт оешмалары урнашкан шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

б) үзләрендә (үз территорияләрендә) гомуми белем бирү оешмалары урнашкан шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

в) каникул вакытында балаларның ялын оештыру өчен кирәкле булган шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

г) үзләрендә (үз территорияләрендә) мәктәпкәчә белем бирү оешмалары урнашкан шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

д) үзләрендә (үз территорияләрендә) медицина оешмалары урнашкан шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

е) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру өчен билгеләнгән шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

4) мәдәният өлкәсендә:

а) тарихи-архитектура, сәнгати, фәнни һәм мемориаль кыйммәткә, шәһәр округы тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия булган, шәһәр округы территориясендә урнашкан, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар, аларның территорияләре һәм аларны саклау зоналары;

б) шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагында булган мәдәни-ял итү билгеләнешендәге объектлар, шул исәптән үзләрендә (үз территорияләрендә) музейлар, театрлар, күргәзмә заллары, мәдәният йортлары, халыкның ял итү үзәкләре, китапханәләр, концерт заллары, филармонияләр, кинотеатрлар урнашкан объектлар;

5) шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле рәвештә башка өлкәләрдә:

а) шәһәр округы чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның зыяннарын бетерү өчен, шулай ук гражданнар оборонасы, халыкны һәм шәһәр округы территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

б) су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

в) шәһәр округының җирле үзидарә органнарының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге вәкаләтләре нигезендә шәһәр округы чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү гамәлләрен оештыру һәм тормышка ашыру өчен билгеләнгән объектлар;

г) шәһәр округы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү өчен билгеләнгән объектлар;

д) үзләрендә (үз территорияләрендә) эшчәнлекләре бердәм җитештерү-технология процессы кысаларында гамәлгә ашырыла торган сәнәгать, агросәнәгать предприятиеләре яисә берничә предприятие урнашкан шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

е) шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы гаражлар, парковкалар, күпкатлы машина кую урыннары, логистика үзәкләре, склад территорияләре;

ж) элемтә объектлары, сәүдә объектлары, базар комплекслары, үзләрендә (үз территорияләрендә) җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте һәм коммуналь хезмәт күрсәтү предприятиеләре урнашкан шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы объектлар;

з) шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагында булган җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар;

и) шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагында булган җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләре;

к) шәһәр округының җирле үзидарә органнары карамагындагы күмү урыннары, ритуаль хезмәт күрсәтү оешмаларының биналары һәм корылмалары;

л) әлеге өлешнең 1 – 4 пунктларында, шулай ук әлеге пунктның «а» – «к» пунктчаларында күрсәтелмәгән, шәһәр округының җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм шәһәр округының социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясый торган гамәлдәге яисә төзелеше шәһәр округының стратегик планлаштыру документлары белән билгеләнгән шәһәр округын социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле юнәлешләре нигезендә планлаштырыла торган объектлар.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 21 июнь
№ 49-ТРЗ